Гыйзәтуллина, Ф. Җ. Кулъяулыгым-бүләгем, сакла аны сөйгәнем / Ф. Җ. Гыйзәтуллина, Л. Р. Сиразетдинова // Ачык дәрес. Мәктәп. – 2025. – №12 (259). – Б. 17-18.

# Кулъяулыгым - бүләгем, сакла аны сөйгәнем

**Гыйзәтуллина Фирая Җәүдәт кызы**
**Сиразетдинова Ландыш Рафвак кызы**
Яр Чаллы шәһәренең 17 нче балалар китапханәсе

**1 алып баручы.** Хөрмәтле кунаклар! Бүгенге кичәгә җыйналуыбызның максаты онытыла башлаган милли йолаларыбызны искә төшерү, халкыбызның аклык, чисталык, пөхтәлек билгесе булган, инде вакыт җилләре саргайта башлаган кулъяулыкларның тарихы белән танышу.

**2 алып баручы.** Татар халкының тормыш көнкүрешендә нинди генә матур һөнәрләр чәчәк атмаган: данлы зәркән сәнгате, күн мозаикасы, чүлмәкчелек, тукучылык.

Әби - бабаларыбыз мирасы кайда ул? Онытылып беткән калфакларыбыздамы, чыңлавы да җаныбызда гына сакланган чулпы тәңкәләребездәме, әкият итеп кенә сөйләргә калган бишек җырларыбыздамы? Әллә инде кыңгыраулы туй дугаларын бизәгән, сабантуе колгаларында җилфердәгән, яулар кичкән, инде сандык төпләрендә саргая башлаган кулъяулыклардамы?

**1 алып баручы.** Аларның тамыры кайларга барып тоташа соң? Безнең халык әүвәл заманнарда рәсем ясамаган дигән фикер йөри. Әмма әбиләребезнең күз нурларыннан тукылган тукымалар бик матур. Һәр төснең җылысын тоя белүче куллар чиккән кулъяулыклар сокландыргыч. Илаһи рәссамнар гына иҗат итә аладыр мондый матур чигешләрне.

Укучы М.Фәйзуллинаның «Ефәк чәчәк» шигырен укый: Татар хатын кызларыбыз
Эшнең серен белгәннәр.
Кич утырып, җырлар җырлап,
Оста чигү чиккәннәр.
Челтәрле сандык эчендә
Кыйммәтле хәзинәләр.
Армый - талмый хезмәт иткән
Безнең уңган әбиләр.
Илләребез имин булсын,
Матур булсын тормышлар.
Бу мирасны дәвам итәр,
Иң уңганнар, тырышлар.

**2 алып баручы.** Безнең милли үрнәкләребездә илаһи бер олылык, кеше хисләрен табигатькә, алсу-кызыл гөлләргә юлаучы ниндидер сихри көч бар сыман. Кулъяулык бизәкләренә халкыбызның матурлык турындагы уй-хыяллары, якты хисләре салынган. Халкым тегү-чигүгә бик оста булган, шуңа күрә бизәкләрендә ниләр генә юк. Анда үсемлекләр, гөлләр, яфраклар, чәчәк бәйләмнәре урын алган.

Менә шушы гади генә кулъяулык татар хатын-кызларының рухи байлыгын, иҗат-хыялларын, эшкә сәләтен, зәвыгын гына, күрсәтеп калмыйча, тарихны чагылдыручы ядкарь дә булып тора. Кулъяулыкка аулак өйләрнең яме, кызлар күңеленең сафлыгы, беренче сөю хисләре сыйган.

Яшь кызлар ак нурдан, ал шатлыктан торган хисләрен кулъяулыкка чиккән
дә, сөйгәненә бүләк иткән.

**1 алып баручы.** Булган бит заманнар, сөю тикле сөю чигслгән челтәрле кулъяулыкка сыйган! Кызкыркын инә-җепкә тотындымы, яшереп кенә кулъяулык чигү хәстәренә керештеме, димәк, бу өйнең бәхет капкалары ачылган. Әниләр йөрәге генә эчтән жу иткән. Шулай булмыйни, үзләреннән беләләр: пар күгәрченле кулъяулык сөйгән ярлы, парлы итә ләбаса. Аларның да кызларына яулык болгап, моңсуланып озатып калыр көннәре якынлаша икән ич.

**2 алып баручы.** Күңелдәге күпме бизәкне, никадәр хатирәләрне яңарта кулъяулык. Әнә егетләр солдатка китәләр:

Кулъяулыкны тузмый диләр,
Почмагыннан туза икән,
Яшь гомерне узмый, диләр,
Искән җилдәй уза икән.

**1 алып баручы.** Эх, ул яшьлек! Гүзәл дә, кыска да, кабатланмас та ул. Бары тик матур чигешләре генә күңел дәфтәренә мәңгелеккә теркәлеп кала. Алар әледән әле тәүге сөйгән ярга, сөю-сәгадәт хисләренә, вәгъдәләшү кичләренә, чиккән кулъяулыкка барып тоташа. Сөю бизәге чигелгән бу кулъяулыклар да, хисләр шикелле бик үк озак саклана: Кульяулыклы яшьлек турында Туфан Миңнуллинның «Кулъяулык» пьесасыннан өзек карап үтик әле.

**2 алып баручы.** Күңел узган хәтирәләрне яңарта. Әнә егетләр солдатка китәләр. Урам тутырып, гармун өздереп, кулъяулыкларын болгап, авыл әйләнәләр. Олыракларның ишек алларына, өйләренә кереп, хушлашып, хәер-дога алып чыгалар. Картларның да, яшь җилкәнчәкләрнең дә бу мизгелдә күңелләре бердәй сулкылдап куя.

Яшь кызлар солдатка алынган егетләрдән чиккән кулъяулыкларын жәлләмиләр. Боегып китмәсен диюләре. Кемнең кемлеге дә шушы кулъяулыкларны болгап, җырлый-җырлый урам әйләнгәндә беленә инде. Кулъяулык күбрәк булган саен, егет тә данлырак, шөһрәтлерәк һәм кызларның күзен күбрәк яндырган була. Әмма ләкин авыл башын чыгып, машинага утыруга, ул иң кадерле бердәнбер кулъяулыгын гына изи. Йөрәкләр әлеге мизгелдә шулай аңлашып аерылыша. Һәркемгә мәгълүм: бу кулъяулык вәгъдә һәм сөю билгесе булып җилферди.

**2 алып баручы.** Хәтирәләр... хәтирәләр... Яшьлекнең сөю чәчәкләре бөреләнеп кенә килгәндә сугыш кыравы төшкән елларга илтә алар. Туган йортларын, сөйгән ярларын калдырып фронтка китә егетләр. Йөрәк янында, түш кесәсендәге чигүле кулъяулык салкын окопларда ятканда өмет учагы булып җылыта аларны. Сугышның башыннан ахырына кадәр йөри кулъяулык, сугыш кырында, җиңүгә дәрт өсти, яшәргә өмет бирә.

Укучы Ф.Кәримнең «Пионерка Гөлчәчәккә хат» шигырен укый.

**Укучы.** Фронтовик Фуад Сәйфуллин шундый сугыш хәтирәләре белән уртаклаша: дошманның артиллерия һөҗүме барганда күкрәгемә нәрсәдер бәрелде, әмма мин бернинди авырту да сизмәдем. Ату бераз тынгач, карасам, шинелемнең дә, гимнастеркамның, да сул түшендә тишек пәйдә булган. Күкрәк кесәмдә ак кульяулык, дәфтәр, гаиләбез фотосы бар иде. Снаряд ярыгы шуларны тишкән дә, йөрәгемә үтмәгән. Ак кулъяулык әҗәлгә калкан булды дип ышанып әйтә алам.

**Укучы.** Ш.Рәкыйповның «Геройлар үлмиләр» китабында кулъяулык турындагы хәтирәләр менә болай сурәтләнә: «Солдат аркасыннан төшми йөрткән биштәр капчыктагы әйберләр, күкрәктәге, орден-медальләр, кесәләрдәге кадерле истәлек сурәтләр старшинага тапшырыла. Гази истәлеккә дип сөйгәне биреп җибәргән, чиккән кулъяулыкны гына алып кала. Аның өчен шуннан да кадерле нәрсә юк хәзергә. Үткәннәрне хәтердә яңартучы да, арган - талганда көч бирүче дә шул гына кебек аның өчен, сөйгән кызының бүләк кулъяулыгы гүя газиз туган иленең нәкъ бер өлеше».

**2 алып баручы.** Халкыбызның милли сәнгать иҗаты авыр елларда да сүнмәде, сакланып калды. Кулъяулыкларыбыз да әбиләребезнең күңел җылысын саклаган хәлдә киләчәк буыннарга барып ирешсә иде.